Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге Советының егерме өченче утырышы

Кощаково авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

31 март, 2023 ел № 80

«Җир салымы турында» 2017 елның 16 октябрендәге 23 номерлы (2019 елның 28 октябрендәге 59, 2021 елның 22 октябрендәге 34 номерлы карарлар белән расланган үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. «Җир салымы турында» 2017 елның 16 октябрендәге 23 номерлы (2019 елның 28 октябрендәге 59, 2021 елның 22 октябрендәге 34 номерлы карарлар белән расланган үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә

- 3.1 пунктының 2 абзацында «Президент тарафыннан» сүзен «Башлык (Рәис) тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге башлыгы З.Н. Саттарова